СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Тњбђн Мђтђскђ авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

**Иске Кырлай авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**“18” ноябрь 2019 ел** **№123**

**Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 октябрендәге 50 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенең 31 бүлеге, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге Уставы нигезендә Иске Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 октябрендәге 50 номерлы «Җир салымы турында» карарына (Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 2019 елның 21 августындагы 114 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның 3.1.1 пунктындагы беренче абзацында «автомобиль юллары» сүзләреннән соң «, әлеге карарның 2 пунктындагы 2.1 пунктчасында күрсәтелгәннәрдән тыш, " сүзләрен өстәргә»;

2) 4 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасының гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән бер ай үткәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль мәсьәләләр буенча даими эшләүче комиссиягә йөкләргә.

Иске Кырлай авыл җирлеге
башлыгы Ф.Г. Сиражетдинов